КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 06 сентябрь г.Казань № 1084

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Академия» исеменә ия булган театрларда эшләгән өчен түләүләр турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 677 нче карарының кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 6 апрель, 316 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль автоном һәм бюджет яшьләр сәясәте учреждениеләренә грантлар турында нигезләмәдә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Грант турында белешмәләр, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган

(өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

5.2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Грант алучы, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалык бирә;»;

6.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Вәкаләтле орган грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

әлеге карар белән расланган Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләренә грантлар түләү

өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

7 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең күрсәткече;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру тәртибе һәм сроклары;»;

10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Җирле үзидарә органы Министрлыкка финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисапны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча килешү төзүдә каралган срокларда Министрлыкка тапшыра.»;

икенче абзацта «Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече» сүзләрен «Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 29 сентябрь, 1051 нче карары белән расланган Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

10 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты түгел, шул исәптән теркәлү урыны булып офшор компанияләренең Россия Федерациясендә активлар белән

арадаш (офшор) биләү өчен кулланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлеге (алга таба - офшор компанияләре), шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яисә читләтеп катнашу өлеше 25 проценттан артып киткән (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) Россия Федерациясе финанс министрлыгы тарафыннанраслана торган дәүләт һәм территорияләр исемлеге тора. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

11 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айдан алдагы айның 1 көненә бирелгән, сайлауда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмавын раслый торган салым органы белешмәсен;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлауда катнашучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавын раслый торган, сайлауда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган, мөһере белән таныкланган белешмә кәгазе;»;

20 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

20 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин